ГОСУДАРСТВЕННЫЙ КОМИТЕТ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН ПО ТАРИФАМ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ ТАРИФЛАР БУЕНЧА ДӘҮЛӘТ КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

**КАРАР**

12.11.2025 г. Казань № 278-34/тэ-2025

«Электр челтәрләре» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе тарафыннан Азнакай муниципаль районы кулланучыларына җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) тарифлар билгеләү турында

«Җылылык белән тәэмин итү турында» 2010 елның 27 июлендәге 190-ФЗ номерлы федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә бәя билгеләү турында» 2012 елның 22 октябрендәге 1075 номерлы карары, Федераль тарифлар хезмәтенең «Җылылык белән тәэмин итү өлкәсендә җайга салынулы бәяләрне (тарифларны) хисаплау буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 13 июнендәге 760-э номерлы боерыгы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 15 июнендәге 468 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты турында нигезләмә, Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты идарәсенең 12.11.2025 ел, № 23-ПР утырыш беркетмәсе нигезендә Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Әлеге карар кушымтасы нигезендә «Электр челтәрләре» Татарстан Республикасы дәүләт унитар предприятиесе (алга таба – «Электр челтәрләре» ТР ДУП) тарафыннан Азнакай муниципаль районы кулланучыларына җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) тарифлар билгеләргә.

2. Әлеге карарның 1 пунктында билгеләнгән тарифлар карар үз көченә кергән көннән башлап 2025 елның 31 декабренә кадәр гамәлдә була.

3. Бу карар рәсми басылып чыккан көненнән башлап 10 көн узгач үз көченә керә.

Рәис Р.В. Гайнетдинов

Татарстан Республикасы Тарифлар
буенча дәүләт комитетының
12.11.2025 № 278-34/тэ-2025
карарына кушымта

# «Электр челтәрләре» ТР ДУП тарафыннан Азнакай муниципаль районы кулланучыларына җибәрелә торган җылылык энергиясенә (егәрлегенә) тарифлар

| № т/с | Муниципаль берәмлек, җайга салынулы оешма атамасы, тариф төре | Ел | Су | Басым астында сайланма пар | | | | Кискен һәм редукция-ләнгән пар |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | | 1,2 башлап 2,5 $кг/см^2$ кадәр | 2,5 башлап 7,0 $кг/см^2$ кадәр | 7,0 башлап 13,0 $кг/см^2$ кадәр | 13,0 $кг/см^2$ югары | |
| | Азнакай муниципаль районы | | | | | | | |
| 1 | «Электр челтәрләре» ТР ДУП | | | | | | | |
| 1.1 | Кулланучылар өчен, тоташтыру схемасы буенча тарифлар дифференциацияләнмәгән очракта | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 12.11.2025 № 278-34/тэ-2025 карар үз көченә кергән көннән башлап 31.12.2025 кадәр | 2 457,83 | - | - | - | - | - |
| 1.2 | Халык (тарифлар өстәмә хак салымын исәпкә алып күрсәтелгән) <*> | | | | | | | |
| | бер ставкалы, сум/Гкал | 12.11.2025 № 278-34/тэ-2025 карар үз көченә кергән көннән башлап 31.12.2025 кадәр | 2 949,40 | - | - | - | - | - |

<*> Россия Федерациясе Салым кодексының 168 статьясындагы 6 пунктын гамәлгә ашыру максатларында аерып чыгарыла.

Татарстан Республикасы Тарифлар буенча дәүләт
комитетының тариф карарларын кабул итүне
оештыру, контрольдә тоту һәм теркәү бүлеге